Республика Татарстан
Глава Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423655, Менделеевский район, с. Тихоново,
ул. Шишкина, д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге Башлыгы

423655, Менделеевск районы, Тихоново авылы,
Шишкин урамы, 3а

тел./факс 8/85549/3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 октябрь 2024 ел № 2

Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлегенең
Тихоново авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 октябрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә гражданнар җыенын этаплап уздыруны билгеләргә.

1.1. Тихоново авылында яшәүчеләр исемлеген җыен этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Коммунистлар ур., 1 – 43 й. – 15:30 сәг.

Икенче этап: Шишкин ур., 1 - 56 й., Яшьләр ур., 3 – 9 й. Үзәк ур., 5 й. - 16:30 сәг..

Өченче этап: Тойма ур., 1 – 44 й., Урман ур., 1 – 24 й. – 17:30 сәг.

1.2. Гражданнар җыены уздыру урыны итеп Менделеевск районы, Тихоново авылы, Коммунистлар урамы, 27 В йорты адресы буенча урнашкан Тихоново авыл мәдәният йортын билгеләргә.

2. «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга.

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тихоново авылында асфальт һәм бетон түшәмәле юлларны төзекләндерү һәм чокырларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәннән су алу насосы сатып алу);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, триммер сатып алу);

4) коймаларны ремонтлау, кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (авыл зиратында койма монтажлау);

5) урамнарга яктырту җайланмасы алу (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Тихоново авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Тихоново авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов